Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 3 марты 35№

Әлки муниципаль районы Советының
2007 елның 31 маендагы «Татарстан
Республикасы Әлки муниципаль районының
Муниципаль милек реестры турындагы
нигезләмәне раслау хакында» 110 номерлы
карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының муниципаль милеген исәпкә алуны камилләштерү, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру, 1997 елның 21 июлендәге "Күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу турында" 122-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мөлкәткә хокукларны рәсмиләштерүне тәэмин итү максатында Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Советының 2007 елның 31 маенда «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Муниципаль милек реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 110 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында:

- Билгеләнгән Тәртип нигезендә реестрда районның җир кишәрлекләре турында белешмәләр составын билгеләргә.
- Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 3.1.1 пункт белән тулыландырырга:

3.1.1. Реестрдан өземтәләр мөрәҗәгать кергән көннән соң 10 көн эчендә язма мөрәҗәгать нигезендә бирелә»

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин